ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**19.06.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1800**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы территориясендә халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларын булдыру турында» 2020 елның 24 декабрендәге 2535 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетында, Зеленодольск муниципаль районы оешмаларында кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә, 1994 елның 21 декабрендәге «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 68-ФЗ номерлы Федераль закон, гадәттән тыш хәлләрдә халыкны беренче чиратта тормыш белән тәэмин итүне оештыру һәм зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары эшен оештыру буенча методик киңәшләр (Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хаты 15.06.2022, № М11-1541-) нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы халкының гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаганда яки килеп чыкканда вакытлыча күченеп китү чараларын әзерләү һәм үткәрү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы территориясендә халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларын булдыру турында» 2020 елның 24 декабрендәге 2535 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Зеленодольск муниципаль районы территориясендә халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары исемлеген яңа кушымтада бирелгән редакциядә расларга (1 нче кушымта);

1.2.Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы территориясендә халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларын булдыру турында» 2020 елның 24 декабрендәге 2535 номерлы карарының 1 нче кушымтасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. Карарның 4 пунктындагы беренче абзацында «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.В.Лулаковка» сүзләрен «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы Д.А.Нигъмәтуллинга» сүзләренә алмаштырырга.»;

1.4. Карарның 6 пунктындагы беренче абзацында «Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлеге башлыгы А.Р. Ханбиковка» сүзләрен «Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлеге начальнигы О.Е.Хохоринга» сүзләренә алмаштырырга.»;

1.5.Карарның 7 пунктындагы беренче абзацында «Зеленодольск РҮХ» ДАССУ баш табибы вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Мөхәммәтдиновка» сүзләрен

«Зеленодольск РУХ» ДАССУ баш табибы Р.Р. Мөхәммәтдиновка тәкъдим итәргә» сүзләренә алмаштырырга.

1.6. Карарның 9 пунктындагы беренче абзацында «Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Р. З. Хаҗиевка тәкъдим итәргә» сүзләрен «ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге Р.Н.Чибриковага» сүзләренә алмаштырырга;

2. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы А.В.Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2023
елның 19 июнендәге 1800
номерлы карарына
1 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районы территориясендә халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары исемлеге**

| № т/б | Учреждениенең факттагы адресы | Учреждение атамасы | Вакытлыча урнаштыру пунктлары сыйдырышлыгы сыйдырышлыгы (кеше) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| **I категория** | | | | |
| 1 | 422520, Зеленодольск шәһәре Гагарин ур., 1. тел. 8(84371) 5-76-47 | «Идел» профилакторий шифаханәсе | 200 | |
| 2 | 422530, Васильево штп, Санаторий тер. ур, 1а тел. 8(84371) 6-22-25 | «Васильевский » ЛПЧУП шифаханәсе | 200 | |
| 3 | 422530, Васильево штп, Александр Чуркин тыкрыгы, 1 тел. 8(84371) 6-30-05 | «Сосновый бор» шифаханәсе» ҖЧҖ | 130 | |
| **III категория** | | | | |
| 4 | 422540, Зеленодольск шәһәре, Гоголь ур., 40а тел. 8(84371) 5-27-08 | «ТР ЗМР аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 11 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | 230 | |
| 5 | 422530, Васильево штп, Бәйрәм ур., 9 тел. 8(84371) 6-20-05 | ТР ЗМР «Н. Соболев ис. 2 нче Васильево урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | 1000 | |
| 6 | 422532, Васильево штп, Яр буе ур., 17 тел. 8(84371) 6-40-20 | ТР ЗМР «3 нче Васильево урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | 200 | |
| 7 | 422500, Карамалы Тау штп , Совет ур., 108 тел. 8(84371) 2-07-75 | ТР ЗМР «Зөя урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | 200 | |
| 8 | 422513, Мулла Иле авылы, Яңа ур., 4 | ТР ЗМР «Мулла Иле төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | 437 | |

| № т/б | Учреждениенең факттагы адресы | Учреждение атамасы | Вакытлыча урнаштыру пунктлары сыйдырышлыгы сыйдырышлыгы (кеше) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| | тел. 8(84371) 2-41-48 | | | |
| 9 | 422526,<br>Октябрь п.,<br>Мәктәп ур., 1<br>тел. 8(84371) 6-57-02 | ТР ЗМР«<br>Обсерватория урта гомуми белем бирү мәктәбе »МБМУ | 800 | |
| 10 | 422538,<br>Бело-Безводное авылы,<br>Юбилей ур., 14<br>тел. 8(84371) 2-91-23 | «ТР ЗМР Раифа урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | 506 | |
| 11 | 422538,<br>Бело-Безводное авылы,<br>Юбилей ур., 13<br>тел. 8(84371) 2-91-23 | Раифа мәдәният йорты | 300 | |
| 12 | 422511,<br>Татар Танае авылы,<br>Үзәк ур., 48<br>тел. 8(84371) 2-78-37 | ТР ЗМР<br>«А.Шамов ис.Татар Танай урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | 200 | |
| 13 | 422510,<br>Норлат авылы,<br>Мәктәп ур., 1<br>тел. 8(84371) 3-92-84 | «ТР ЗМР Норлат урта гомуми белем мәктәбе» МБМУ | 250 | |
| 14 | 422524,<br>Олы Җәке авылы,<br>Мәктәп ур., 1<br>тел. 8(84371) 6-60-48 | ТР ЗМР<br>«Олы Җәке төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | 200 | |
| | **БАРЛЫГЫ** | **14 вакытлыча урнаштыру пункты** | **4853 кеше** | |